**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле урнаштырылган карантинны бетерү турында

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле урнаштырылган карантинны бетерергә:

а) Татарстан Республикасының түбәндәге торак пунктлары территорияләрендә:

Биектау районының Бәерле авылы;

Биектау районының Чыршы авылы;

б) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә:

Аксубай районының Рус Кармәте авылындагы Үзәк урам;

Алексеевск районының Зур Полянка авылындагы Үзәк урам;

Алексеевск районының Ромодан авылындагы Халык урамы;

Әлки районының Иске Салман авылындагы Вахитов урамы;

Әлки районының Иске Чаллы авылындагы Үзәк урам;

Әлки районының Хлебодаровка авылындагы Прохоров урамы;

Әтнә районының Олы Әтнә авылындагы Бәдри Җиһаншин урамы;

Әтнә районының Иске Мәңгәр авылындагы Каенсар урамы;

Кайбыч районының Бәрлебаш авылындагы Вахитов урамы;

Нурлат районының Төрнәс авылындагы Кызыл Армия урамы;

Питрәч районының Званка авылындагы Яшел урам.

2. Үз көчләрен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Биектау районының Чыршы авылы территориясендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2014 елның 30 декабрендәге ПУ-1188 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Биектау районының Бәерле авылы территориясендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2015 елның 2 гыйнварындагы ПУ-1 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2015 елның 2 гыйнварындагы ПУ-2 номерлы Указы.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2015 ел, 06 март
№ ПУ-248